РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 12 2020 г. №939

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 9 ноябрендәге
854 номерлы карары белән расланган
“Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы муниципаль берәмлеге муниципаль
учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә
хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы
нормаларын үз эченә алган башка норматив
хокукый актларның үтәлешенә ведомство
контроле турында Нигезләмә”сенә үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында " 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә һәм - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив-

хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 09.11.2020 ел, № 854 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль учреждениеләрендә һәм предприятиеләрендә хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле турындагы Нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль учреждениеләрдә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан үткәрелә торган гамәлләрнең (административ процедураларның) срокларын һәм эзлеклелеген, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты оешмаларында хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен(алга таба - ведомство контроле, вазыйфаи зат) гамәлгә ашыру буенча эшче төркем белән хезмәттәшлек тәртибен билгели.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

Якупов Р. М.
2-74-14